Татарстан Республикасы Хисап палатасы

Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2017 елдагы эшчәнлеге турында ХИСАП

Казан – 2018 ел

Эчтәлек

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге .....……...3

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге .....……....15

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары, Тышкы финанс тикшерүенең региональ органнарының Европа оешмасы белән үзара хезмәттәшлек .....……..39

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары союзы белән үзара хезмәттәшлек ……..…43

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек.....…….....45

Эшчәнлектә хәбәрдарлык……..…48

Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2017 елдагы эшчәнлеге турында ХИСАП

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эшчәнлеге турында хисап Татарстан Республикасының 2004 елның 7 июнендә кул куелган “Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” 37-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 33 маддәсе нигезендә әзерләнде.

Хисапта 2017 елда закон тарафыннан билгеләнгән бурычларны һәм вәкаләтләрне үтәү буенча Хисап палатасы тарафыннан башкарылган эшчәнлек нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге

2017 елда Татарстан Республикасы бюджетын һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетын (алга таба – Татарстан Республикасы ММИ территориаль фонды) формалаштыру һәм үтәүне тикшерү кысаларында 81 тикшерү һәм экспертиза-аналитика чарасы үткәрелде, 75 объект тикшерелде.

Уздырылган чаралар нәтиҗәләре буенча **80 бәяләмә** әзерләнде, шулардан:

- **Татарстан Республикасы законнары проектлары һәм башка норматив хокукый актлар экспертизалары** – 34 бәяләмә;

– Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында **еллык хисапны тикшерү** һәм 2016 ел өчен бюджет чараларының төп администраторларының **бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерү** кысаларында – 39 бәяләмә;

- 2017 елның 1 кварталында, 1 ярты еллыгында һәм 9 ае өчен Татарстан Республикасы **бюджеты үтәлешенең мониторингы** кысаларында – 3 бәяләмә;

- 2016 ел өчен **Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү** кысаларында – 1 бәяләмә;

- 2017 елның 1 кварталында, 1 ярты еллыгында һәм 9 ае өчен **Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты үтәлеше мониторингы кысаларында** – 3 бәяләмә.

Хисап елында программаларны тормышка ашыруның гамәлдәге күрсәткечләренә бәяне, аларның Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегик максатларына ирешүгә йогынтысын, дәүләт программаларын финанслау күләмен корреляцияләүгә һәм аларны тормышка ашыруның ирешелгән нәтиҗәлелек индикаторларына бәяне үз эченә алган **Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыру барышына мониторинг** ясау дәвам иттерелде.

Россия Федерациясе стратегик үсешенең 12 юнәлеше буенча дәүләт секторында федераль дәрәҗәдә проект принципларын кертү һәм тормышка ашыру белән бәйле рәвештә Хисап палатасы тарафыннан республика территориясендә **өстенлекле проектлар һәм программаларны эшкәртү һәм тормышка ашыру барышына мониторинг** оештырылды һәм үткәрелде.

2017 елда **Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты, бюджетлар һәм бюджетлар үтәлеше турында законнарга үзгәрешләр кертү турында законнарның 11 проектына** экспертиза уздырылды.

«2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проектына экспертиза барышында закон проекты һәм закон проекты белән бер үк вакытта бирелгән документларның бюджет законнарына туры килү, керем һәм чыгымнар өлеше күрсәткечләренең, кытлыкны финанслау чыганакларыннан җәлеп ителә торган чаралар күләменең нигезләнгән булуы мәсьәләләре каралды.

Экспертиза йомгаклары буенча бюджет проектының республика Министрлар Кабинеты резерв фонды күләме, бюджет кытлыгы, файдаланулар күләме, дәүләт бурычы һәм аңа хезмәт күрсәтүгә

чыгымнар өлешендә бюджет законнары билгеләгән чикләүләрне истә тотып формалашуы билгеләнде.

2018-2020 елларга республика бюджеты проекты балансланган. Хисап палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетының планлаштырыла торган кытлыгын каплау өчен бюджет исәпләрендә калган чараларның җитәрлек булуын раслана.

2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар планлы вакыт аралыгына республика бюджеты проектын эшләгәндә нигез итеп алынган төп макроикътисадый күрсәткечләр фаразы федераль дәрәҗәдә билгеләнгән сценар шартларны истә тотып формалаштырылган. Фаразда, бюджет законнары таләпләренә яраштырып, 2017 елга республика бюджеты проектын төзегәндә кабул ителгән 2018-2019 еллар параметрлары тәгаенләнгән һәм 2020 ел параметрлары өстәлгән.

Республика икътисадында трендлар үзгәрү, макроикътисадый күрсәткечләрне тәгаенләү белән бәйле рәвештә Хисап палатасы тарафыннан стратегик планлаштыру документларын килештерү максатында Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр Социаль-икътисадый үсешенең озак вакытка исәпләнгән фаразы күрсәткечләрен актуальләштерергә тәкъдим ителде.

Республика бюджетының керем өлеше гамәлдәге салым һәм бюджет законнары нигезендә формалаштырылган. Бәяләмәдә федераль дәрәҗәдә планлаштырыла торган салым буенча льготалар саклану һәм аерым акцизлар язып кую һәм бүлү тәртибе нормативлары өлешендә үзгәрешләр бюджетның төп параметрларына һәм аларның балансылыгына йогынты ясаячагы билгеләп үтелә.

Бюджетның чыгым өлеше республиканың чыгым йөкләмәләре реестрын исәпкә алып формалаштырылган.

2018 елга бюджет проектында социаль әһәмияткә ия чыгымнар чыгымнарның гомуми күләменнән 72% тәшкил итә һәм халыкка дәүләт ярдәме чаралары комплексын саклауны тәэмин итә.

Республиканың ачык норматив йөкләмәләрен үтәүгә каралган чыгымнар, законнар таләпләренә яраклаштырылып, инфляция дәрәҗәсен исәпкә алып индексацияләнде.

Республика бюджеты проектын формалаштырганда Россия Федерациясе Президентының май указларында билгеләнгән күрсәткечләргә ирешү максатларында бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең аерым категорияләренең хезмәт хакын арттыру буенча чаралар күрүне финанс белән тәэмин итү каралган.

2018 ел бюджетының программа өлеше бюджет чыгымнарының гомуми өлешенең 89,7 процентын тәшкил итә һәм республиканың 29 дәүләт программасын тормышка ашыруга ассигнованиеләрне үз эченә ала. 2018-2020 елларда программа чыгымнарының төп күләме «Кеше капиталы» юнәлешенә туры килә, бу 2017 елның 21 сентябрендә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына булган еллык юлламасында яңгыраган республиканың социаль-икътисадый үсешенең төп юнәлешләре белән яраша.

Аерым дәүләт программалары буенча экспертиза кысаларында бюджет проектында каралган һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларында расланган финанслау күләмнәренең туры килмәве ачыклана. Шуңа бәйле рәвештә Хисап палатасы бәяләмәсендә 2018-2020 елларга республика бюджетын раслаганнан соң дәүләт программалары параметрларын билгеләнгән тәртиптә тәгаенләү кирәклеге билгеләп үтелә.

«2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе Территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектына экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча закон проектының билгеләнгән тәртиптә расланган 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы территориясендә Гражданнарга

бушлай медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы булмаган шартларда формалаштырылуы билгеләп үтелде.

Закон проекты бюджет проектын формалаштыруга һәм аның эчтәлегенә булган таләпләргә туры килә. Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты керемнәренең фаразланган күләмнәре һәм аның дефицитын финанслау чыганакларыннан килгән кертемнәр фондның чыгымнарының фаразланган күләменә туры килә, бюджет дефициты күләме бюджет законнары белән билгеләнгән чикләрдән артып китми.

Хисап елында **«2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында»** законнарының 4 проектына **экспертиза үткәрелде.**

Кертелгән үзгәрешләр үз чыгымнары буенча фараз күрсәткечләрен тәгаенләүнең зарурлыгы, Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан кертемнәргә һәм күрсәтелгән чаралар исәбенә башкарыла торган чыгымнарга төзәтмәләр кертү, шулай ук калган максатчан чаралар исәбенә расланган чыгымнарны беркетү, дәүләт программалары, бюджет чараларын төп бүлүчеләр арасында бюджет чараларын яңадан бүлү белән бәйле. Бюджет күрсәткечләренә төзәтмәләр кертү барышында бюджет законнары белән билгеләнгән чикләүләр һәм таләпләр сакланган.

«2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законнары проектларына экспертизалар нәтиҗәләре буенча (законнарның өч проекты) закон проектларында тәкъдим ителгән үзгәрешләр объектив характерда һәм салым һәм салым булмаган керемнәрнең, Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан чараларның чынбарлыкта керүе, узган елларның калган максатчан чаралары һәм нормалаштырылган иминият запасы чаралары исәбенә башкарыла торган чыгымнарны беркетү, шулай

ук бюджет ассигнованиеләрен чыгымнар классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре арасында күчерү белән бәйле булуы ачыкланды.

Татарстан Республикасының **«2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында»** һәм **Татарстан Республикасының «2016 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында»** законнары проектларына экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча закон проектлары күрсәткечләренең Хисап палатасының тышкы яктан тикшерүен үткән Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисаплар күрсәткечләренә туры килүе расланды.

Законнар проектлары һәм аларның кушымталары составлары һәм эчтәлекләре буенча бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләре саклаган хәлдә формалаштырылган.

Хисап елында **Татарстан Республикасы законнарының,** шул исәптән республиканың салымнар һәм җыемнар турында законнары, бюджетара мөнәсәбәтләр мәсьәләләренә кагыла торган **21 проектына,** финанс-икътисадый **экспертиза** үткәрелде.

Үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре билгеләнгән вакытларда Хисап палатасының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелгән бәяләмәләрендә чагылыш тапты.

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт тикшерүе һәм күзәтчелеген тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына бәяләмәдә финанслау күләмнәрен ачыклаганда дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен ачыклау өчен законнар белән расланган нормативларны исәпләү методикасын куллануның, шулай ук баланслылыгын саклау максатларында Татарстан Республикасы бюджетының өстәмә чыгымнарын каплау өчен чыганакларны ачыклау зарурлыгы турында билгеләп үтелде.

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына бәяләмәдә аны кабул иткән очракта финанс-икътисадый нигездә закон үтәлешенә чараларның җитәрлек булуын раслый торган исәпләүләрнең булмавы билгеләп үтелде.

«Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы аерым икътисадый зонаның һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән техник-гамәлгә кертү тибындагы «Иннополис» аерым икътисадый зонасы оешма-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына бәяләмәдә закон проектын кабул иткән очракта республиканың консолидацияләнгән бюджетының килеп чыгарга мөмкин булган «төшеп кала торган» керемнәренә бәйле рәвештә 2017 елга Татарстан Республикасы бюджеты балансылылыгын саклау өчен өстәмә каралар таләп ителгәнлеге күрсәтелә.

«2018 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыручы региональ коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы закон проектына экспертиза кысаларында региональ коэффициентның зурлыгы федераль дәрәҗәдә билгеләнә торган коэффициент-дефляторны исәпкә алып саналырга тиеш булуы билгеләп үтелә. Закон проекты формалашкан вакытка әлеге күрсәткеч расланмаган иде. Шуңа бәйле рәвештә федераль дәрәҗәдә 2018 елга коэффициент-дефляторның зурлыгы исәпләүләрдә кулланылганнан башка төрле (үзгә) кабул ителгән очракта региональ коэффициентның кыймәтен тәгаенләү таләп ителәчәк.

Хисап елында **«2016-2018 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызга үз теләкләре буенча Татарстан Республикасына**

күчеп кайтуга ярдәм итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы проектына финанс-икътисадый экспертиза үткәрелде.

Экспертиза тәкъдим ителгән дәүләт программасы Хисап палатасы тарафыннан «2016-2018 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызга үз теләкләре буенча Татарстан Республикасына күчеп кайтуга ярдәм итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы проектына бәяләмәдә чагылыш тапкан тәкъдимнәрне истә тотып әзерләнгән.

Аерым алганда, һәр программа чарасы буенча финанслауның күләмнәре һәм чыганакларын ачыклауга тәкъдимнәр, программа чараларын (уку, йөрү, яшәү, медицина ярдәме күрсәтүнең бәясе) тормышка ашыру кысаларында куела торган хезмәт күрсәтүне ачыклауга кабул ителгән якын килүләр, шулай ук программа нәтиҗәлелегенең сан (бәяләү) күрсәткечләрен еллар буенча бүлеп кертү исәпкә алынган.

Шулай ук Хисап палатасының программаны тормышка ашыруда катнаша торган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзара хезмәттәшлеге тәртибен көйли торган нигезләмәләрне, шулай ук дәүләт программасында катнашучыларның җир кишәрлекләре алу тәртибен дәүләт программасына кертү турында тәкъдимнәре исәпкә алынган.

Хисап палатасына йөкләнгән бурычлар нигезендә хисап елында **Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджетының** агымдагы **үтәлешен** тикшерү кысаларында квартал саен мониторинг үткәрелде.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджетының агымдагы үтәлешенең мониторинглары кысаларында салым һәм салым булмаган керемнәр, кире кайтарылмый торган максатчан чараларның керүенә, чыгым йөкләмәләре үтәлешенә, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларыннан җәлеп ителгән чаралар күләменә, алдагы елның шундый ук күрсәткечләре белән чагыштырмада бюджетлар үтәлешенең төп күрсәткечләре динамикасына, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты турында законнарының текст маддәләре үтәлешенә, аларны тормышка ашыруны тәэмин итү максатында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларны әзерләү һәм кабул итүнең үз вакытында булуына анализ ясалды.

2017 елның 9 ае эчендә Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше мониторингы йомгаклары буенча бюджет керемнәре 170 млрд. сум күләмендә керүе билгеләп үтелде. Алдагы ел күрсәткечләре белән чагыштырганда керемнәрнең үсеше 9,2% тәшкил итә.

Бюджет керемнәрендә төп өлешне оешмалар табышына салым, физик затлар табышына салым, акцизлар буенча кертемнәр тәшкил итте. Бюджетның керемнәр өлешенең үз керемнәре хисабына 89,1% ка үтәлеше алынган чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә республиканың финанс мөстәкыйльлеге өчен шартлар тудыра.

Анализ ясала торган вакыт аралыгы өчен бюджет чыгымнары 157,5 млрд. сум тәшкил итә. 2016 елның шул ук вакыт аралыгы күрсәткече белән чагыштырганда чыгымнар буенча 8,2% ка үсеш күзәтелә.

Бюджетның чыгымнар өлеше 2017 елга закон белән расланган структура нигезендә башкарылган. Бюджет үтәлешен оештырганда, тулаем алганда, чыгымнарның кварталлар буенча тигез бүленүе тәэмин ителә.

Чыгымнарның төп күләмен – 97%ны республиканың дәүләт программаларын тормышка ашыруга чыгымнар тәшкил итте. Шул ук вакытта аерым дәүләт программалары буенча чыгымнар 50% тан да азрак башкарылуы ачыкланды. Моңарга бәйле рәвештә бәяләмәдә нәтиҗәлелекнең расланган индикаторларына ирешү өчен башкаручылар тарафыннан программа чараларын үз вакытында үтәү буенча чаралар кабул итү кирәклеге билгеләп үтелде.

Мониторинглар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр Хисап палатасы Коллегиясе тарафыннан расланды һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителде.

2017 елда **2016 ел өчен Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыруга** аларны тормышка ашыру турында еллык хисаплар нигезендә **мониторинг** уздырылды.

Тикшерү барышында дәүләт программаларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең дөрес булмау, дәүләт программаларын тормышка ашыру турындагы хисапларда каралган финанслау күләмнәренең республиканың 2016 ел өчен бюджет күрсәткечләренә туры килмәү очраклары ачыкланды.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына формалаштыра торган документларның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итү буенча чаралар күрү кирәклеге турында хатлар җибәрелде.

Республика хөкүмәтенә дәүләт программаларын тормышка ашыру вакытында эш нәтиҗәләренә йогынты ясарлык системалы куркынычлар турында мәгълүмат бирелде.

Бюджет законнары нигезендә хисап елында **2016 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисапка** тышкы яктан тикшерү үткәрелде, ул бюджет чараларының 41 төп кулланучысының, бюджет керемнәренең төп администраторының (алга таба – бюджет чараларының төп администраторлары) бюджет хисаплылыгын тикшерүне үз эченә алды.

2016 ел өчен бюджет үтәлеше турында хисап һәм аның белән бергә бирелә торган документларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тышкы яктан тикшерү үткәрү өчен үз вакытында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97.4 маддәсендә билгеләнгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Хисап палатасына җибәрде.

Төп администраторларның еллык бюджет хисабы Еллык, квартал һәм айлык хисапларны төзү һәм бирү тәртибе турында 191н инструкциясе таләпләрен истә тотып төзелгән һәм 2016 елга кабул ителгән бюджет классификациясе кодлары буенча формалаштырылган.

Тышкы яктан тикшерү нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә керемнәр, чыгымнар күләме һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча 2016 ел өчен Татарстан Республикасы бюджет үтәлеше турында хисап күрсәткечләренең бюджет чараларының төп администраторларының еллык бюджет хисабының җыелма күрсәткечләре һәм 2017 елның 1 гыйнваренә торышы буенча Татарстан Республикасы бюджетының

җыелма бюджет росписе күрсәткечләре белән туры килүе билгеләп үтелә.

2016 елда республика бюджеты керемнәре 220 238,2 млн. сум, чыгымнары – 222 230,1 млн. сум, кытлык – 1 992 млн. сум тәшкил итте.

2016 елда республика бюджетын үтәгәндә бюджет кытлыгы, дәүләт бурычы, дәүләт бурычына хезмәт күрсәтүгә чыгымнар зурлыгы буенча бюджет законнары билгеләгән чикләүләрне саклау тәэмин ителә.

2016 ел өчен Республика бюджеты үтәлеше турында хисап күрсәткечләреннән законнар тарафыннан расланган билгеләнешләрдән тайпылышлар объектив характерда, аларның барлыкка килү сәбәпләре бюджет законнаары белән билгеләнгән нигезләргә туры килә.

Шулай итеп, башкарылган чыгымнар буенча күрсәткечнең 493,5 млн. сумга артып китүе хисап елында республика бюджетына расланган билгеләнешләрдән артык кергән федераль бюджет һәм ММИ Федераль фондының өстәмә максатчан чараларын, шулай ук узган еллардан калган максатчан чараларны үзләштерүгә бәйле.

697 млн. сум күләмендә чыгымнарның аерым төрләренең үтәлмәве әлеге күрсәткечкә ел саен йогынты ясый торган факторларга бәйле: подрядчыларның башкарган эшләренең актларын тапшырмавы (330 млн. сум күләмендә), дәүләт ярдәмен алучыларның чынбарлыктагы санының фаразланганнан шактый кимрәк булуы (250 млн. сумнан артык хаҗәт булмый), бәйге процедуралары уздыру йомгаклары буенча экономия (130 млн. сум).

2016 ел йомгаклары буенча федераль бюджетның файдаланылмаган максатчан чараларының күләме 5,5 млн. сум, ягъни 0,02% тәшкил итте, шуларның 3 млн. сумнан артыгы чараларны бирүнең гаризалар буенча бирелүенә бәйле рәвештә аларга, шул исәптән торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә; гражданнарның аерым категорияләренә вакытлыча хезмәткә сәләтлелеген югалту очрагына пособиеләр түләүгә ихтыяҗ булмый.

2016 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты үтәлеше турында хисапны тышкы яктан тикшерү йомгаклары буенча 2016 ел өчен еллык хисапта Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты үтәлеше турында мәгълүматларның дөрес булмау яисә тулы булмау очраклары ачыкланмады.

2016 ел өчен Татарстан Республикасы бюджетының үтәлеше турында Хисапны һәм 2016 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты үтәлеше турында хисапны тышкы тикшерү йомгаклары Хисап палатасы Коллегиясендә каралды һәм расланды, 2016 ел өчен Татарстан Республикасы бюджетының үтәлеше турында Хисапка Бәяләмә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, 2016 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Фонды бюджеты үтәлеше турында хисапка Бәяләмә – Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителде.

Хисап вакыты аралыгында Хисап палатасы тарафыннан тышкы яктан дәүләт финанс тикшерүенең (ТДФТ) ике стандарты эшләнде.

«Чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елы һәм планлы вакыт аралыгына) Татарстан Республикасы бюджет проектына экспертиза уздыру» ТДФТ стандарты тарафыннан чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елы һәм планлы вакыт аралыгына) Татарстан Республикасы бюджет проектына экспертиза уздыру тәртибе билгеләнә, закон проектына экспертизаның максатлары, бурычлары, мәгълүмати базасы, шулай ук закон проектына бәяләмә төзелеше һәм аның эчтәлегенә төп таләпләр ачыклана.

«Тикшерү һәм экспертиза-аналитика чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тикшерү» ТДФТ стандарты белән Хисап палатасы уздырган чараларның (күрсәтмәләр, киңәшләр, административ хокук бозулар турында беркетмәләр, мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында хәбәрнәмәләр, мәгълүмати хатлар) нәтиҗәләрен тормышка ашыруның төп кагыйдәләре һәм тикшерүне оештыру һәм тормышка ашыру процедуралары билгеләнә.

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге

Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына караган учреждениеләрдә, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек, Транспорт һәм юл хуҗалыгы, Юстиция, Мәгълүматлаштыру һәм элемтә, Сәламәтлек саклау министрлыкларында, Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфатына карата дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясендә, «Татарстан Республикасы Торак-коммуналь хуҗалык фонды»нда, шулай ук Әлмәт, Баулы, Югары Ослан, Яңа Чишмә, Сарман һәм Спас муниципаль районнарында тикшерү чаралары үткәрелде. Барлыгы 497 объект тикшерелде.

Хисап палатасының тикшерү-ревизия эшчәнлегенең төп күрсәткечләре таблицада китерелә:

Күрсәткеч атамасы	2016 ел	2017 ел
Үткәрелгән тикшерү-ревизия чараларының саны	53	54
Тикшерү-ревизия чаралары үткәргәндә җәлеп ителгән объектлар саны (берәмлек)	494	497
Бозуларның ачыкланган күләме (мең сумнарда)	1 563 950,8	2 040 371,2
Чаралар бюджетка кайтарылган һәм чаралар күрелгән (мең сумнарда)	1 363 516,6	1 974 676,6
Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча прокуратура һәм хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны (берәмлек)	53	54
Хисап палатасы тикшерүләре материаллары буенча суд һәм башка вәкаләтле органнар тарафыннан административ җаваплылыкка тарту турында кабул ителгән карарлар саны	98	114
Хисап палатасы материаллары буенча кузгатылган җинаять эшләре саны	5	3

Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча Хисап палатасы тарафыннан республика муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары белән берлектә дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләре өчен сатып алынган югары технологияле медицина җиһазларын файдалануның нәтиҗәлелегенә карата мониторинг уздырылды.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнарында балалар бакчалары төзелешенә, үзгәртеп кору һәм капиталь ремонтка бүлеп бирелгән, медицина учреждениеләрен һәм гражданнарның аерым категорияләрен дару чаралары, медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны тикшерү уздырылды.

Хисап палатасы (эксперт төркеме составында) **Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты Идарәсе** белән берлектә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (коррекцияле интернат-мәктәпләр, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» ДБУ), Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына («Татарстан Республикасы Мәдәни мирас үзәге» ДБУ) караган учреждениеләрдә, профсоюзларның «Бәкер» ДПУда, шулай ук Яшел Үзән, Менделеевск, Тукай муниципаль районнарында коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыруда практик ярдәм күрсәтү буенча комплекслы чаралар уздыруда катнашты.

Татарстан Республикасы Прокуратурасы йөкләмәсе буенча аерым оешмаларның кече һәм урта эшмәкәрлеккә (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы) дәүләт ярдәме рәвешендә субсидияләр бүленүнең законлылыгын һәм максатчан куллануны, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы эшчәнлегенең аерым мәсьәләләрен тикшерү уздырылды.

Россия Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Теннис федерациясе эшчәнлеген тикшерү үткәрелде.

Идел буе транспорт прокуратурасы (Казан һәм Кама бүлекләре) мөрәҗәгате буенча 2017 елга транспорт системасын үстерү буенча региональ программаларны тормышка ашырганда бюджет законнарын саклауны тикшерү уздырылды.

Татарстан Республикасында Терроризмга каршы комиссиянең эксперт группасы составында Хисап палатасы Алексеевский һәм Актаныш муниципаль районнарында тикшерүләрдә катнашты.

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы эшчәнлегендә законнар саклануны тикшерү уздырылды.

«Россия өчен» Халык фронты Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Региональ бүлеге мөрәҗәгате буенча Биектау муниципаль районының Семиозерка авыл җирлегенең Озерный торак пунктында күлне чистарту буенча эшләргә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын файдалануны тикшерү уздырылды.

2017 елда тикшерү эшчәнлеге барышында ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне квалификацияләү белешмә-методик документ буларак Россия Федерациясе Хисап палатасы коллегиясе хуплаган Тышкы дәүләт аудиты (тикшерүе) барышында ачыклана торган бозуларның классификаторын кулланып тормышка ашырылды.

Уздырылган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча гомуми күләме **2 040 371,2 мең сум** булган **бозулар;** шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты чаралары буенча – 712 538,4 мең сум, муниципаль берәмлекләр бюджетлары – 787 189,7 мең сум, башка чаралар – 540 643,1 мең сум күләмендә ачыкланды,

Комплекслы һәм тематик тикшерүләр уздырганда түбәндәге бозулар ачыкланды:

- дәүләт (муниципаль) милек белән идарә итү һәм файдалану вакытында бозулар – 848 104,1 мең сум;
- бухгалтерлык (бюджет) исәбен һәм хисаплылыгын бозулар – 620 881,6 мең сум;
- бюджетларны формалаштыру һәм үтәү вакытында бозулар – 164 832,5 мең сум;
- дәүләт (муниципаль) сатып алуларын тормышка ашырганда киткән бозулар – 199 981,2 мең сум;
- бюджет чараларын нәтиҗәсез файдалану – 112 728,0 мең сум;
- бюджет чараларын максатсыз файдалану – 185,0 мең сум;
- башка бозулар (субсидия алучыларның хисапларын бирмәү, бюджет законнарын башка бозулар) – 93 658,8 мең сум.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан
2017 ел өчен уздырылган тикшерү чаралары барышында ачыкланган
финанс бозуларының төзелеше

2014-2015 елларда һәм 2016 елның узган вакыт аралыгында **кадетлар гомуми белем бирү учреждениеләрендә патриотик һәм хәрби тәрбиягә** бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын файдалануның нәтиҗәлелегенә **аудит нәтиҗәләре буенча** хисап вакыт аралыгында 15 кадетлар белем бирү учреждение булуы, аларда 3 992 тәрбияләнүче укуы билгеләп үтелде. Кадетларны патриотик һәм хәрби тәрбияләүгә тикшерелә торган вакыт аралыгы эчендә 945 млн. сум акча җибәрелгән.

Уздырылган социологик сораштыру нәтиҗәләре белем бирү хезмәтләренең сыйфаты, педагогларның компетентлыгы һәм һөнәри осталыгы белән канәгатьлекнең югары дәрәҗәсен күрсәтә. Ата-аналарның

күпчелеге (97%) укытучыларның үз вазифаларын яхшы башкаралар дип саный. Белем бирү учреждениеләре эшенең функциональлеге (сыйфаты) сораштыручыларның 85 процентын канәгатьләндерә. Сорашуда катнашкан педагоглар учреждениеләрдә белем бирү процессы укучыларга патриотик тәрбия бирү буенча максатлар һәм бурычларга ирешергә ярдәм итә дип саныйлар. Мәктәпләр биналарының торышы белән укучыларның 73 проценты канәгать.

Шуның белән бергә учреждениеләрдә тикшерүләр барышында бухгалтерлык исәбенең товар-матди байлыкларны исәпкә алуда чагылдырмау, хисап мәгълүматларын бозып күрсәтү, бюджет чараларын дебиторлык бурычына тарту белән бәйле бозулары, касса операцияләрен алып баруны бозулар ачыкланды.

Кирәк булмаган милек (автотранспорт, көнкүреш һәм органик техника, укыту, спорт, медицина җиһазлары) ачыкланды.

Мәсәлән, «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов исемендәге Васильево кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУдә уку процессында гомуми бәясе 177,9 мең сум булган автомат өйрәтү комплексы, гомуми бәясе 49 мең сум булган автотренажерлар, 29,3 мең сумлык ышкылау-кисү станогы, 22,7 мең сумлык МОК-300 бәрәңге чистарткыч, күчермә ясый торган җайланма, сумкасы белән 4 данәдә VirtualInkMimioProfessional интерактив приставкалары, 2 берәмлек MimioTeach интерактив приставкалар файдаланылмый.

«Советлар Союзы Герое И.Н. Конев исемендәге Чирмешән кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ дә гомуми бәясе 203,5 мең сум булган 15 берәмлек верстак, 33,6 мең сумлык 24 укучыга Votum-25 L2672 сорашу һәм тестлар уздыру системасы файдаланылмый.

«Карпов Павел Алексеевич исемендәге Болгар кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ дә 68,7 мең сумлык интерактив сенсорлы модуль, гомуми бәясе 454,9 мең сум булган технология кабинеты өчен комплекс кирәк булмый, шул исәптән тиешле бина булмау сәбәпле 149,9 мең сумлык универсаль кыру станогы, гомуми бәясе 203,5 мең сум булган 15 верстак,

гомуми бәясе 89 мең сум булган инструментлар наборы, гомуми бәясе 11,0 мең сум булган файдаланышта булмаган.

«Советлар Союзы Герое Чирков Михаил Алексеевич исемендәге Кама Тамагы кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ дә 3 елдан артык үз максатында файдаланылмаган гомуми бәясе 1 006,9 мең сум булган физика кабинеты өчен җиһазлар комплекты төп чаралар составында саналган.

«Советлар Союзы Герое Б.К. Кузнецов исемендәге Казан кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ нең медпунктында, махсус җиһазландырылган бина һәм әлеге җиһазларда эшләү өчен укыган медицина персоналы булмау сәбәпле, 5 елдан артык файдаланылмаган гомуми бәясе 150,9 мең сумлык физиотерапия процедуралары үткәрү өчен җиһазлар булу ачыкланды.

«Советлар Союзы Герое Б.К. Кузнецов исемендәге Казан кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ да файдаланылмый торган медицина җиһазлары

Сатулашулар уздырмыйча гына, кечкенә күләмдәге сатып алуларга норматив лимиттан артык килешүләр төзү, шулай ук азык-төлек продуктларын югары бәяләрдән сатып алу фактлары ачыкланды.

Аерым кадетлар мәктәпләрендәге биналар укыту хезмәтләре күрсәтүнең тиешле дәрәҗәсен ачыклый торган таләпләргә туры килми. Тикшерелгән учреждениеләрнең күпчелегендә капиталь яисә агымдагы ремонт уздыру таләп ителә. Күп кенә учреждениеләрдә спорт, мәдәни-массакүләм чаралар уздыру өчен аерым биналар, фәннәрне укыту өчен җиһазландырылган кабинетлар юк.

Мәсәлән, «Советлар Союзы Герое Михаил Алексеевич Чирков исемендәге Кама Тамагы кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ дә, тренажер залы булмау сәбәпле, спорт тренажерлары укытучылар бүлмәсендә урнашкан.

«Советлар Союзы Герое Михаил Алексеевич Чирков исемендәге Кама Тамагы кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ нең укытучылар бүлмәсендә урын алган спорт тренажерлары

Аудит нәтиҗәләре турында хисап Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре катнашында киңәшмәдә каралды.

Министрлык кадетлар белем бирү оешмаларында укыту-методик, тәрбия һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге торышы мониторингын оештырды, ачыкланган бозуларны һәм кимчелекләрне бетерү буенча системалы эш алып барыла.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча финанс-хуҗалык эшчәнлеген һәм белем бирү хезмәтләренең сыйфатын тикшерү булмауда чагылыш тапкан вазыйфаи бурычларын тиешле дәрәҗәдә башкармаулары өчен «Советлар Союзы Герое Б.К. Кузнецов исемендәге Казан кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ, «Советлар Союзы Герое Николай Волостнов исемендәге Васильево кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ һәм «Генерал-майор Владимир Аверкиевич Хапаев исемендәге Тәтеш кадетлар интернат-мәктәбе» ДББББУ директорлары башкарган вазыйфаларыннан азат ителде.

2013-2016 елларга Татарстан Республикасында юл эшләре үткәрүгә бүлеп бирелгән дәүләт чараларын файдалануның нәтиҗәлелегенә аудит йомгаклары буенча 2013-2016 еллар өчен юл тармагын финанслауның Татарстан Республикасы бюджеты хисабына гомуми күләме 90 782,4 млн. сум тәшкил итүе билгеләнде.

Күрсәтелгән вакыт аралыгы эчендә 186 км юл салынды, 305 км реконструкцияләнде, 4 006 км ремонтланды, 838 метр озынлыгындагы 10 яңа күпер төзелде, 183 метр озынлыгындагы 5 күпер реконструкцияләнде, 192 км ясалма яктырту урнаштырылды.

Шуның белән бергә, 2017 елның 1 гыйнваренә карата эксплуатацияләүгә кертүгә рөхсәт булмауга бәйле төзелеше тәмамланган һәм чынбарлыкта файдаланыла торган гомуми бәясе 79 040,5 мең сумлык 7 объект күчемсез милеккә кертемнәр составында санала иде.

Татарстан Республикасы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгының 2013 елның 21 гыйнварендә кул куелган 62-р номерлы күрсәтмәсе белән алга таба муниципаль районнар милкенә тапшыру өчен шактый гына автоюллар «Главтатдортранс» ДКУ дәүләт милке исемлегеннән төшерелгән. Шул ук вакытта 2016 елның 1 гыйнваренә карата гомуми бәясе 114 232,3 мең сум булган автоюллар муниципаль берәмлекләргә тапшырылмаган.

2017 елның 1 гыйнваренә карата гомуми күләме 112 677,6 мең сум булган 2000-2001 елларның 48 берәмлек проект-тикшеренү эшләре күчемсез милеккә кертемнәр составында санала.

Сайланма тикшерүләр гомуми күләме 1 142,3 мең сум булган башкарылган юл эшләренең бәясен арттырып күрсәтүнең аерым фактларын ачыклады.

Мәсәлән, Балык Бистәсе районында төзелгән юлларның аерым участокларында юл киеме астына тагарак төзү буенча җир эшләре башкарылмаган (подрядчы оешма: «Русремстрой» ҖЧҖ).

Югары Ослан муниципаль районының Килди һәм Мәйдан авылларында юл киеме төзегәндә Патрикәй авылыннан көньяк-көнчыгыштарак урнашкан санкцияләнмәгән карьердан китерелгән 700 м^3 күләмендә ком файдаланылган. Карьерның эшкәртү тирәнлеге 5 метрдан

артып киткән, авыр техника эшләгән эзләр һәм тигезләнгән килү юллары бар. Ком чыгару ачык ысул белән башкарылган (подрядчы оешма: «Волгадорстрой» ҖЧҖ).

Патрикәй авылы янында санкцияләнмәгән карьер

Тикшерү барышында ачыкланган бозулар юкка чыгарылды – санкцияләнмәгән карьердан чыгарылган комның бәясе суммасын юкка чыгаруга актлар төзелде һәм төзелеш объектына ком китерү буенча чыгымнар кабул ителде.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы уздырган аудит йомгаклары буенча юл тармагында эчке тикшерү системаларының ышанычлылыгын, бюджет чараларын файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр комплексы әзерләнде.

Аудит нәтиҗәләре турында хисап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Нәтиҗәлелек аудиты нәтиҗәләре буенча җибәргән бозулары һәм кимчелекләре өчен, башкару документациясен үз вакытында рәсмиләштермәгәннәре өчен «Главтатдортранс» ДКУ нең күпер корылмалары буенча эшләрне кабул итү һәм сыйфатын тикшерү бүлеге башлыгы, эшләрне кабул итү һәм сыйфатын тикшерү бүлеге башлыгы урынбасары һәм баш белгече дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

2013-2017 елларга Татарстан **Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерүгә** бүлеп бирелгән дәүләт чараларын файдалануның **нәтиҗәлелегенә аудит** нәтиҗәләре буенча «2013 -2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) чараларын

тормышка ашыруга тикшерелгән вакыт аралыгы эчендә 6 612,0 млн. сум чара, шул исәптән федераль бюджет чаралары хисабына – 2 098,0 млн. сум, Татарстан Республики бюджетыннан – 639,5 млн. сум, җирле бюджетлар – 16,0 млн. сум, бюджеттан тыш чаралар – 3 858,5 млн. сум бүлеп бирелүе билгеләнә.

Күрсәтелгән вакыт аралыгы эчендә газ-мотор ягулыгында эшли торган гомуми бәясе 5 452,5 млн. сум булган, шул исәптән бюджет чаралары – 2 658,9 млн. сум, бюджеттан тыш чаралар исәбенә – 2 793,6 млн. сум, 1 033 транспорт чарасы сатып алынган.

2016 ел һәм 2017 елның 9 ае эчендә Дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында 1 298 автотранспорт чарасы, шуларның 471 автотранспорт чарасы бюджет өлкәсендә, газ-мотор ягулыгына яңадан җиһазландырылган.

Республикада 19 автомобиль газ тутыру компрессор станциясе эшләде. Татарстан Республикасында кысылган табигый газны файдалану күләме 2017 елның 9 ае эчендә 20,5 млн. куб. метр тәшкил итә, бу 2013 елның шундый күрсәткеченнән 3 тапкыр артып китә.

Газ-мотор ягулыгында эшли торган автобусларны эксплуатацияләүгә уздырылган мониторинг аларның, дизель ягулыгында эшли торган автобуслар белән чагыштырганда, икътисадый һәм экология ягыннан нәтиҗәле булуын күрсәтте.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы әйдәп баручы тармак белгечләре белән берлектә Дәүләт программасын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрү буенча тәкъдимнәр әзерләде.

Нәтиҗәлелек аудиты уздыру барышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 28 октябрендә кул куелган 2815-р номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына Дәүләт программасына төзәтмәләр кертү йөкләмәсе бирелде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы **сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле булган балалар өчен белем бирү учреждениеләренең** эшчәнлеген тәэмин итүгә

бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын файдалануны тикшерү йомгаклары буенча дәүләт милке белән идарә итү һәм аннан файдалану өлкәсендә гомуми күләме 24 559,4 мең сум булган аерым бозулар ачыклана.

Е.Г. Ласточкина исемендәге Казан интернат-мәктәбендә үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итүгә тоташкан вакыттан бирле (2004 ел) котельный бинасы, шулай ук баланс бәясе 2 007 мең сум булган башка дәүләт милке (гараж, слесарьлек кишәрлеге) файдаланылмаган.

Ун интернат-мәктәпнең төп чаралары составында кулланылудан чыккан, рухи яктан искергән гомуми баланс бәясе 4 195,7 мең сум булган җиһазлар (оргтехника, аудио- һәм видеоаппаратура, кухня һәм уку җиһазлары, спортинвентарь) сакланган.

Е.Г. Ласточкина исемендәге Казан интернат-мәктәбендә һәм 7 нче номерлы Казан интернат-мәктәбендә 2015 елда республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгы үзәкләштерелгән сатып алган 262,8 мең сумлык 163 берәмлек карават файдаланылмаган.

Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак интернат-мәктәбенең төп бинасында башкарылган ремонт эшләренең сыйфатын тикшерү барышында түшәмнең бөтен мәйданы буенча бинага атмосфера явым-төшеме үткәннән соң калган эзләр булуы ачыкланды. Түшәмне җылыту буенча сыйфатсыз башкарылган эшләрнең бәясе 899,5 мең сум тәшкил итә.

Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак интернат-мәктәбендә түшәмне җылыту буенча эшләрне сыйфатсыз башкару

Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан уздырылган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча ачыкланган бозуларны киләчәктә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан җибәрмәү һәм профилактика максатында ведомство карамагындагы тикшерелгән учреждениеләр җитәкчеләре һәм баш хисапчылары белән киңәшмә үткәрелде. Җибәрелгән бозулар һәм кимчелекләр өчен ведомство карамагындагы 11 вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Бухгалтерлык исәбен алып бару, бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын төзүдә ачыкланган бозулар очраклары буенча белем бирү учреждениеләренең 8 вазыйфаи затына карата административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзелде.

Махсуслаштырылган (наркологик) медицина ярдәме күрсәтүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чараларын файдалануны тикшерү «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркологик диспансеры» (алга таба – Учреждение) ДАССУ эшчәнлегендә дәүләт контрактларын үтәгәндә, наркология диспансерының бинасын тоту, авыруларны палаталарда урнаштыру, туклану нормаларын саклау буенча бозулар һәм кимчелекләр җибәрелүе ачыклады.

Мәсәлән, аерым биналар авыруларга медицина ярдәме күрсәтүләрнең тиешле дәрәҗәсен билгели торган таләпләргә туры килми.

Диспансер бинасы һәм бүлмәләренең канәгатьләндермәслек торышы

Авыруларны санитария-эпидемиология таләпләре тарафыннан билгеләгәннән түбәнрәк мәйданлы (1 кешегә 6 кв. метр) палаталарда урнаштыру очраклары булган.

2013 елның 5 апрелендә кабул ителгән 44-ФЗ номерлы Федераль законны бозып, гомуми суммасы 4 349 мең сум булган контрактларның билгеләнгән үтәлү вакытлары сакланмый, күп кенә очракларда тәэмин итүнең вакытын бозулар 5 айдан узып китә. Учреждение дәүләт контрактларын үз вакытында үтәмәүләре өчен неустойка түләтү хокукыннан файдаланмый. Административ хокук бозулар билгеләре булган әлеге факт буенча тикшерү материаллары Россия Федерациясенең Монополиягә каршы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрелде.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Учреждениесенең Баш табибына ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне юкка чыгару һәм алга таба аларны булдырмау буенча нәтиҗәле чаралар кабул итү зарурлыгына басым ясалды. Тикшерү барышында ачыкланган бозулар өчен диспансерның 3 хезмәткәренә дисциплинар җәза бирелде.

«2011-2015 елларга һәм 2015-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының **«Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»** подпрограммасы чараларын тормышка ашыруга җибәрелгән бюджет чараларын 2014-2016 елларда файдалануның нигезле булуын тикшерү Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондында, Казан шәһәренең Авиатөзелеш һәм Яңа Савин, Вахитов һәм Идел буе, Совет, Киров һәм Мәскәү районнары хакимиятләрендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең, Арча, Әлмәт, Бөгелмә, Түбән Кама, Чистай һәм Ютазы муниципаль районнарының башкарма комитетларында уздырылды.

Финанслауның иң зур күләмнәрен Казан шәһәре – 43% һәм Яр Чаллы шәһәре – 24%. алды.

2014 елда 67 яшь гаиләгә, 2015 елда – 70 гаиләгә, 2016 елда – 81 гаиләгә социаль түләүләр бирелде, тикшерү вакытына шулардан 77 яшь гаилә фатир алмаган иде.

Яшь гаиләнең торак өчен түләү һәм йортларның чынбарлыкта файдалануга тапшыру вакытлары арасындагы аерма программаның үз вакытында үтәлүенә комачаулый. Өстәвенә программада республика

районнары арасында чараларны бүлү муниципаль берәмлектә һәркем алырлык торакның булуыннан чыгып бүленергә тиешлеге карала.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча республиканың Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына күрсәтмә бирелде.

Тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондына, Татарстан Республикасы Прокуратурасына җибәрелде.

«**2014-2020 елларга музей эшен үстерү**» подпрограммасы буенча Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча мәдәният учреждениеләрендә бюджет чараларын һәм дәүләт милкен файдаланган вакытта гомуми суммасы 47 383,5 мең сум булган бозулар табылды.

Аерым учреждениеләрдә файдаланылмый торган биналарны һәм корылмаларны хуҗалык әйләнешенә тарту, ликвид булмаган активларны гамәлдән чыгару буенча үз вакытында һәм нәтиҗәле чаралар күрелмәгән.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы Милли музее» ДБМУда 2007 елның апреленнән файдаланылмый торган (янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозулар булу сәбәпле) Казан шәһәре, Чернышевский урамы, 6/2 йорты адресы буенча урнашкан, калган бәясе 13 775,3 мең сум булган бинаны хуҗалык әйләнешенә кертү буенча чаралар күрелмәгән, 2015 елда алынган бәясе 178 мең сум булган мультимедиа җиһазы файдаланылмаган, бәясе 190 мең сум булган антиквар савыт-саба экспозициягә куелмаган.

«Ленино-Кокушкино» Дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» ДУсендә, учреждениенең 2016 елның ноябрь аеннан үзәкләштерелгән газ белән җылытуга күчүе сәбәпле, гомуми бәясе 479,7 мең сум булган электр-җылыту җиһазы кирәкми торганга әйләнгән.

«Иске Казан дәүләт тарихи-мәдәни һәм табигать музей-тыюлыгы» ДУндә бухгалтерлык исәбендә учреждение территориясендә урнашкан тарихи-мәдәни һөнәрчелек комплексының төп чаралары объектлары чагылыш тапмаган.

Бухгалтерлык исәбен һәм хисаплылыгын тупас бозуларның ачыкланган очраклары буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзелде.

Тикшерү барышында шулай ук сатып алулар өлкәсендә гомуми күләме 10 391,4 мең сум булган бозулар ачыкланды.

Шулай, «Алабуга дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» ДУндә 2015 елда музей чаралары уздыру буенча хезмәт күрсәтүләргә гомуми бәясе 640 мең сум булган өч килешү алар чынбарлыкта эшләнгәннән соң төзелгән.

Моңардан тыш, «Россия рәссамнар Союзы»ның Башкортостан Республикасының төбәк бүлеге тарафыннан 2016 елның июнендә Алабуга музей-тыюлыгы түләгән бәясе 200 мең сум булган каталогларны билгеләнгән вакытка китерелмәгән (тикшерү уздырганнан соң тулы күләмдә китерелгән).

«Татарстан Республикасы Милли музее» ДБМУның 2015 елда «Созидание» Остаханәсе» ҖЧҖ белән (Казан шәһәре) «А.М. Горький исемендәге әдәби-мемориал музей» ДБМУ да экспозиция булдыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән 9 265 мең сумлык дәүләт контрактын үтәгәндә башкаручы тарафыннан контрактта каралмаган материалны алмаштыру, экспозициянең аерым элементларын үтәмәү кебек кимчелекләр җибәрелгән.

«Татагролизинг» А**Җнең** финанс-хуҗалык эшчәнлегенең законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшерү тарафыннан 2016 елда акционерлык җәмгыятендә 2015 ел белән чагыштырганда керемнең 25%ка, чиста табышның – 39 %ка кимүен һәм 1,7 млн. сум тәшкил итүен ачыкланды.

2014-2016 еллар эчендә лизинг түләүләре кертемнәренең гомуми суммасы 722,7 млн. сум тәшкил итте.

Дебиторлык бурычлылыгының зурлыгы соңгы 3 елда иң кечкенә кыймәтенә җитте һәм 4 144,7 млн. сум тәшкил итте. Шул ук вакытта срогы чыккан дебиторлык бурычлылыгының өлеше әһәмиятле булып кала – 50% яъни 2 129,2 млн. сум. 2016 ел өчен 112 808,0 мең сум

күләмендә зыянга түләтүгә реаль булмаган дебиторлык бурычлылыгы исәптән төшерелә, шуларның 42 550,0 мең сумы – «Алтын башак» ҖЧҖ артында, 4 594,3 мең сумы – «Байкал» ҖЧҖ артында санала.

«Татагролизинг» АҖ балансында складка 3 елдан артык элегрәк кергән гомуми бәясе 234,6 млн.сум булган матди товар байлыклаыр исәпләнә.

«Татагролизинг» АҖнең бүлендек җәмгыятьләрендә («Лениногорская» Агрофирмасы» ҖЧҖ, «Ялтау» Агрофирмасы» ҖЧҖ) уздырылган каршы як тикшерүләр тарафыннан бухгалтерлык исәп-хисабын алып бару тәртибен һәм хисаплар төзүдә аерым бозулар ачыкланды.

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында үткәрелгән комплекслы тикшерү чаралары йомгаклары буенча гомуми күләме **770 241,5** мең сум булган бозулар һәм кимчелекләр ачыкланды, гомуми күләме **727 583,1 мең сум** булган бюджет чараларын тоткан вакытта, республика (муниципаль) милекне кулланганда ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне юкка чыгару һәм башка финанс бозулары буенча чаралар күрелде (бозуларның ачыкланган күләменнән 94,5%).

Комплекслы тикшерү чаралары барышында муниципаль милек белән идарә итү һәм аннан файдалану өлкәсендә бозулар һәм кимчелекләр ачыкланды.

Шулай итеп, Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендә эксплуатацияли торган оешмага бәясе 38 735,9 мең сум булган субүлгечләре белән сууткәргеч корылмалар, бәясе 15 834,1 мең сум булган 6 урам буенча сууткәргеч челтәрләр билгеләнгән тәртиптә тапшырылмаган.

Баулы муниципаль районында муниципаль милектән нәтиҗәсез файдалану, булган матди активларны хуҗалык әйләнешенә тарту яисә аларны вакытында гамәлдән чыгару буенча кирәкле кабул итмәү очраклары ачыкланды.

Мәсәлән, муниципаль район Советы тарафыннан, 2015 елның ноябреннән бирле техник җитешсезлекләре булу сәбәпле, баланс бәясе 348,5

мең сум булган Hyundai Accent автомашинасы (2006 елда чыгарылган) файдаланылмаган.

«Райсервис» ААҖнең төп чаралары составында гомуми бәясе 4 644,1 мең сум булган авыл җирендә күпфатирлы йортларны җылыту өчен 2001-20012 елларда төзелгән 12 блоклы котельный санала. 2006 елда, күпфатирлы йортларның ике контурлы шәхси җылытуга күчүе сәбәпле, әлеге объектлардан файдалану тукталган.

Котельныйларда урнаштырылган җиһазлар яңадан торгызырлык түгел (техник паспортлар буенча казаннарның хезмәт итү вакыты 10 елдан артык түгел). Шул ук вакытта котельныйлар предприятиеләрнең устав фондында тора, аларның торышы канәгатьләнерлек түгел һәм кешеләр өчен куркыныч тудыра.

Поповка һәм. Кырымсарай авылларындагы котельныйлар

Шулай ук акционерлык җәмгыяте балансында баланс бәясе 497,5 мең сум булган авыл җирлеге хокук билгеләүче документлардан башка файдалана торган «Кырымсарай авылын су белән тәэмин итү» объекты да санала. Тикшерү барышында Баулы муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы карары буенча суэтем челтәрләре «Райсервис» ААҖ нән алынды һәм Кырымсарай авыл җирлеге башкарма комитетының оператив идарәсенә тапшырылды.

Баулы шәһәрендә 2009 елдан бәясе 8 311 мең сум булган Укыту-җитештерү комбинаты бинасы файдаланылмаган.

Укыту-җитештерү комбинатының файдаланылмый торган бинасы

Тикшерелү чорында бинаны файдалануга кертү яисә сату буенча чаралар күрелмәде.

Баулы шәһәренең Төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча идарәсе озак вакыт буена гомуми бәясе 5 301 мең сум булган транспорт чаралары, биналар, җиһазларны файдалану яисә гамәлдән чыгару буенча чаралар күрмәгән.

Сарман муниципаль районында эксплатацияләүче оешмалар тарафыннан гомуми бәясе 88 378,6 мең сум булган су, җылылык һәм газ белән тәэмин итүнең инженерлык челтәрләренең кайбер объектлары тиешле хокук билгеләүче документларсыз файдаланылган, шул исәптән:

- «Азнакай җылылык челтәрләре предприятиесе» ААҖ аренда килешүләре (концессияләр һәм башкалар) төземичә генә Сарман авылында һәм Җәлил ш.т.б. дә гомуми бәясе 66 357,9 мең сум булган инженерлык челтәрләреннән файдаланган;

- «Җылылык челтәрләре» ҖЧҖ аренда килешүләре (концессияләр һәм башкалар) төземичә генә гомуми бәясе 22 020,7 мең сум булган газүткәргечләрнең инженерлык челтәрләреннән файдаланган.

Муниципаль районнарда тикшерүләр үткәрү барышында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне максатсыз файдалану, гомуми таралган файдалы казылмаларны чыгару буенча санкцияләнмәгән карьерлар, каты көнкүреш калдыклары чүплекләре эшләү фактлары ачыкланды.

Әлмәт муниципаль районы территориясендә җирләрне, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге дә, максатсыз файдалану, вак

таш, ком чыгару буенча санкцияләнмәгән карьерлар эшләү, шулай ук җирләрне чүп-чар түгү өчен файдалануның 20 очрагы ачыкланды.

Шулай итеп, Кәләй авылы һәм Югары Акташ авыллары арасындагы карьер территориясендә карау вакытында туфрак алу буенча эшләр алып барылганлыгы, йөк техникасы булуы ачыкланды.

Кәләй һәм Югары Акташ авыллары арасында гамәлдә булган карьер

Елховой авыл җирлеге янында чүп-чар ташлау урыны ачыкланды.

Тикшерү материаллары җир тикшерү өлкәсендә бирелгән вәкаләтләр кысаларында җавап кайтаруның тиешле чараларын күрү өчен Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына җибәрелде.

Административ хокук бозулар очраклары буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан Н.Е. Токарликов исемендәге АҖ нә карата РФ нең Административ хокук бозулар турындагы кодексының 7.3.маддәсенең «Җир асты байлыкларыннан лицензиясез файдалану» дип аталган 1 өлеше нигезендә 800 мең сум күләмендә штраф рәвешендә административ җаваплылык чаралары күрелде.

Сарман муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы сатулашулар уздырмыйча гына ООО «Нуркәй» АФ ҖЧҖ, «Джалиль» АФ ҖЧҖ, «Сарман» АФ, «Туган як» АФ на гомуми мәйданы 18 702,4 га булган чикләре билгеләнмәгән авыл хуҗалыгы җирләрен 1 га өчен 48,0 сум аренда түләве белән арендага бирә, бу Сарман муниципаль районындагы шундый ук кишәрлекләрнең аренда бәясеннән ике тапкыр түбәнрәк. Тикшерү барышында муниципаль районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы

тарафыннвн чикләре билгеләнмәгән җирләрнең 1 га өчен аренда түләве 48,0 сумнан 99,6 сумга күтәрелгән.

Муниципаль районнарда бюджет исәбен алып баруны, бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын төзү һәм бирүне бозулар, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгының Бюджет классификациясен куллану тәртибе турында күрсәтмәләрен бозулар җибәрелгән.

Баулы муниципаль районында гомуми күләме 2 062 мең сум булган чыгымнарны түләү бюджет классификациясенең дөрес булмаган кодлары буенча үткәрелгән.

Яңа Чишмә районының өч авыл җирлеге (Акъяр, Яңа Чишмә һәм Петропавел авыл җирлекләре) башкарма комитетлары гомуми күләме 3 549,4 мең сум булган бюджет классификациясенең туры килми торган кодлары буенча чыгымнарны түләү үткәрә.

Муниципаль хаҗәтләр өчен заказларны үтәү өлкәсендә бозулар башлыча товарларның китерү вакытларын, сыйфатын, бәясен һәм ассортиментын саклау, штраф санкцияләре таләпләрен куймау өлкәсендә төзелгән контрактларның шартларын дәлилсез үзгәртү белән бәйле.

Мәсәлән, Баулы муниципаль районында, кабул ителгән килешү йөкләмәләрен бозып, «Атлас» ҖЧҖ (Яр Чаллы шәһәре) 2016 елның декабрендә Баулы шәһәре башкарма комитеты түләгән 235 мең сумлык юл билгеләре урнаштыру буенча хезмәтләрне башкармаган. Баулы шәһәренең Төзекләндерү һәм яшелләндерү идарәсе тарафыннан гомуми күләме 495 мең сум булган биш килешү буенча Александровка авыл җирлегенең урам челтәрләре юлын өлешчә сибү буенча 2016 елның 31 октябренә кадәр каралган йөкләмәләрне үтәлмәгән.

Яңа Чишмә муниципаль районының Петропавел авыл җирлеге башкарма комитеты Петропавел Бистәсендәге күперне норматив халәткә китерү буенча эшләрнең арттырылган күләмен кабул итә һәм подрядчыга («Альянс Д» ҖЧҖ, Казан шәһәре) түли.

Шулай ук, төзелгән муниципаль контрактларны бозып, Яңа Чишмә районының белем бирү учреждениеләренә гомуми бәясе 2 902,7 мең сум булган китерелгән продуктларның сыйфатын раслый торган тиешле

документларсыз ит китерелгән (китерүчеләр – «Талисман» ҖЧҖ һәм ИЭ Махеев).

Сарман муниципаль районында гомуми бәясе 952,8 мең сум булган төзекләндерү объектларын һәм инженерлык челтәрләрен ремонтлау һәм төзү буенча башкарылган эшләрнең бәясен арттыру ачыкланды. Тикшерү барышында барлык бозу очраклары буенча хезмәтләрнең башкарылмаган күләмнәрен юкка чыгару буенча актларга кул куелды, 109,8 мең сумлык чараларның бер өлеше җирле бюджет керемена күчерелде.

Биектау муниципаль районындагы Семиозерка авыл җирлегенең Озерный торак пунктында күлне чистарту буенча хезмәтләргә бүленеп бирелгән бюджет чараларын файдалануны тикшерү тарафыннан 2014 елда аукцион йомгаклары буенча Семиозерка авыл җирлеге башкарма комитеты һәм «Күптармаклы предприятие – МП» ҖЧҖ арасында күлне чистарту буенча хезмәтләр башкаруга контракт төзелүен ачыкланды. Башкарылган хезмәтләр кабул ителгән, җирлек башкарма комитеты башлыгы тиешле актка имзасын куйган. Эшләрнең бәясе 100 мең сумнан артык күләмне тәшкил иткән.

Шул вакытта уздырылган чаралар күлнең чистаруын тәэмин итмәгән. Күлне чистарту вакытында башкарылган эшләрнең бәясен арттыру 785,1 мең сум тәшкил иткән.

Тикшерү йомгаклары буенча Семиозерка авыл җирлеге башлыгына күрсәтмә җибәрелде, тикшерү чарасы материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

Башкарылган хезмәтләрнең күләмен арттыру факты буенча Биектау муниципаль районы прокуратурасы тарафыннан билгеләнмәгән затларга карата Россия Федерациясе Җинаять кодексының 3 өлеше 159 маддәсендә («Караклык») каралган җинаять билгеләре буенча җинаять эше кузгатылды.

Уздырылган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекләр башлыкларына Хисап палатасы тарафыннан ачыкланган бозуларны юкка чыгаруны тәэмин итү буенча чаралар күрү өчен күрсәтмәләр җибәрелде. Аларны карау йомгаклары буенча муниципаль берәмлекләр башлыклары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре тарафыннан бюджет чараларын һәм муниципаль милекне файдаланганда ачыкланган бозулар һәм кимчелекләр фактлары буенча җавап кайтаруның тиешле чаралары күрелде.

Мәсәлән, Хисап палатасының тикшерү материаллары Спас муниципаль районында әлеге райондагы коррупциягә каршы тору буенча коррекция эше комиссиясендә каралды.

Дисциплинар җәзалар башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына, мәгариф бүлеге башлыгына, үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчесенә, «Олимп» балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе җитәкчесенә, Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә һәм район башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгына игълан ителгән.

Әлмәт, Баулы, Югары Ослан, Яңа Чишмә, Сарман һәм Спас муниципаль районнарының учреждениеләре һәм оешмаларының вазыйфаи затларына карата административ хокук бозулар турында 106 беркетмә төзелде.

2017 елда министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренә, муниципаль берәмлекләр башлыкларына Хисап палатасы тарафыннан **23 күрсәтмә** һәм **69 мәгълүмати хат** җибәрелде.

Ачыкланган барлык бозулар турында мәгълүмат һәм үткәрелгән тикшерү чаралары материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына җибәрелде.

2017 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы уздырган тикшерү нәтиҗәләре буенча бюджет чараларын тоткан вакытта, республика, муниципаль милектән файдаланганда гомуми суммасы **1 974 676,6 мең сум** булган **ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне юкка чыгару буенча чаралар күрелгән** (бозуларның ачыкланган

күләменең – 96,8%, 2016 елның шундый ук вакыт аралыгы эчендә – 87%).

Күрелгән чаралар күләменең һәм ачыкланган бозуларның күләменең үзара нисбәте



2017 елда Хисап палатасының вазыйфаи затлары тарафыннан **административ хокук бозулар турында 160 беркетмә** төзелде, бу 2016 елның шундый күрсәткеченнән 1,4 тапкыр артып китә.

Аларны Әлмәт, Актаныш, Апас, Арча, Баулы, Алабуга, Яшел Үзән, Кама Тамагы, Лениногорский, Яңа Чишмә, Нурлат, Сарман һәм Спас суд районнарының, Казан шәһәренең Вахитов, Мәскәү һәм Совет районнарының мировой судьялары, шулай ук Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча Идарәсе тарафыннан карау нәтиҗәләре буенча **55 вазыйфаи зат һәм 2 юридик зат** гомуми күләме **1 203,6 мең сум** булган штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылды:



Хисап палатасы һәм прокуратура күрсәтмәләре буенча **72 вазыйфаи зат** дисциплинар җаваплылыкка тартылды, **3 вазыйфаи зат** биләгән вазыйфасыннан азат ителде.

Тикшерү материаллары буенча Россия Федерациясе Җинаять Кодексының «Караклык» дип аталган 159 маддәсе һәм «Вазыйфаи вәкаләтләрне законсыз файдалану» дип аталган 201 маддәсе буенча **3 җинаять эше кузгатылды.**

Хисап палатасының иң зур әһәмияткә ия булган тикшерү чаралары һәм эшчәнлек нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдим ителде.

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары, тышкы финанс тикшерүе региональ органнарының Европа оешмасы белән үзара хезмәттәшлек

2017 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасының Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, региональ тикшерү-хисап органнары, шулай ук тышкы финанс тикшерүе региональ органнарының Европа оешмасы (алга таба – ЕВРОРАИ) белән үзара хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту буенча эше дәвам иттерелде.

Февраль аенда Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы Президиумы Карары белән Совет комиссияләренең персональ составы расланды: методология мәсьәләләре буенча комиссиягә – Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы А.Р.Вәлиев, хокукый мәсьәләләр буенча комиссиягә республика Хисап палатасының юридик бүлеге башлыгы С.А. Козина кертелде.

Хисап вакыт аралыгында Коллегия әгъзалары, Хисап палатасы структура бүлекчәләре, аерым муниципаль тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре өйрәтү семинарларында, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советының комиссия утырышларында, шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы һәм Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары Порталында видеоконференция форматында булып үткән Россия Федерациясе Хисап палатасы утырышларында катнашты.

Апрельдә Хисап палатасы Рәисе Алексей Демидов Краснодарда узган «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маенда кул куелган аерым Указларын тормышка ашыруга тышкы дәүләт (муниципаль

тикшерүе. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүләрнең һәм ирешелгән нәтиҗәләрнең сыйфатын бәяләү» темасына багышланган фәнни-гамәли конференциясендә катнашты һәм Хисап палатасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпьфункцияле үзәкләрен (КФҮ) булдыруга һәм үстерүгә бүлеп бирелгән дәүләт чараларын файдалануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрү тәҗрибәсе турында доклад белән чыгыш ясады.

23 майда Казанда ЕВРОРАИның «Спорт өлкәсендә дәүләт инвестицияләренә аудит» темасына багышланган халыкара семинар узды. Чарада 12 чит илдән (Австрия, Бразилия, Бөекбритания, Венгрия, Германия, Испания, Литва, Нидерланд, Норвегия, Польша, Франция, Швейцария), Россия Федерциясенең 24 субъектыннан тышкы финанс тикшерүе региональ органнары вәкилләре, шулай ук Россия Хисап палатасы вәкилләре катнашты.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов семинарда Хисап палатасы белән даими, эшлекле, һөнәри әңгәмә режимында торуын, шулай ук Хисап палатасы һәм ЕВРОРАИның хезмәттәшлеге эшне камилләштерүгә һәм аның нәтиҗәлелеген күтәрәчәгенә хезмәт итүенә ышанганлыгын билгеләп үтте.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе Алексей Демидов семинарда катнашучыларга Россия Федерациясе Хисап палатасы Рәисе Т.А. Голикованың котлау адресын тапшырды. А.Демидов үз чыгышында республикада югары казанышлар спортын үстерүгә, физик культура белән шөгыльләнүнең киң таралуын арттыруга, сәламәт яшәү рәвеше өчен шартлар булдыруга юнәлдерелгән дәүләт максатчан программалары һәм проектларының эзлекле тормышка ашырылуын хәбәр итте. Хисап палатасы әлеге юнәлеш буенча бюджет чараларын тотуны тикшерүне финанс аудиты һәм нәтиҗәлелек аудиты уздыру юлы белән тормышка ашыра.

Үзенең чыгышы барышында ЕВРОРАИ Президенты – Луара Җиренең Региональ Хисап палатасы (Франция) җитәкчесе Франсуа Монти спорт инфраструктурасын булдыру буенча Татарстанның алдынгы тәҗрибәсен күрсәтте, семинар ахырында Татарстан Хисап палатасы Рәисенә чараны һөнәри оештыруы өчен рәхмәтен белдерде.

Июнь аенда Хисап палатасы Рәисе Петербург халыкара икътисадый форумы кысаларында модераторы булып Россия Федерациясе Хисап палатасы торган «Проектлы планлаштыру һәм бюджет процессында аның нәтиҗәлелеге» темасына аудиторлык панель сессиясендә катнашты.

Июльдә Татарстан Хисап палатасында Россия Федерациясе Президенты Администрациясе һәм Вьетнам Социалистик Республикасы Хөкүмәтенең Тикшерү идарәсе делегациясе белән эшлекле очрашу булды. Алар Казанга Россиягә рәсми визит кысаларында коррупциягә каршы эшне оештыру буенча республика тәҗрибәсе белән танышу өчен килде.

Очрашу барышында Алексей Демидов Татарстанның тышкы дәүләт финанс тикшерүе югары органының коррупциягә каршы тору буенча эштә катнашу төрләре турында сөйләде.

Вьетнам делегациясе җитәкчесе, Вьетнам Хөкүмәтенең Тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасары Нго Ван Кхан Хисап палатасының төрле юнәлешләрдә шундый зур эш башкаруына, шул исәптән бөтенроссия һәм халыкара хезмәттәшлеккә исләре китүен билгеләп үтте.

Сентябрьдә Татарстан Хисап палатасы Рәисе А.И. Демидов Севастопольдә Россия Хисап палатасы каршындагы РФ Тикшерү-хисап органнары Советы Президиумы утырышында, юл фондлары ассигнованиеләрен формалаштыру һәм үтәлешен тикшерүне оештыру, шулай ук «Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» өстенлекле проектын тормышка ашыру барышын тикшерү практикасына багышланган тикшерү-хисап органнары җитәкчеләренең семинар-киңәшмәсендә катнашты.

Булып узган чаралар барышында Татарстан һәм Севастопольнең тышкы финанс тикшерүе органнары арасында хезмәттәшлек һәм үзара ярдәм турында килешүгә кул куелды.

Сентябрьдә Нальчик шәһәрендә шулай ук Татарстан һәм Кабардино-Балкариянең тикшерү-хисап органнары арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды.

Октябрьдә Севилье шәһәрендә (Испания) ЕВРОРАИның «Электрон хөкүмәт һәм дәүләт аудиты – анализ һәм гамәлият» темасына багышланган чираттагы халыкара семинары узды.

Семинарда Россия Федерациясе делегациясе составында Рәис Алексей Демидов җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы Хисап палатасы вәкилләре дә катнашты.

Декабрьдә Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов Россия Хисап палатасы Рәисе Татьяна Голикова җитәкчелегендә узган Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы

Тикшерү-хисап органнары Президиумы һәм Советының берләштерелгән утырышында катнашты.

Утырышта «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законына үзгәрешләр кертү тәкъдимнәре буенча фикер алышу узды, Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенә бәя (анализ) бирү турындагы Нигезләмә, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы турындагы Нигезләмәгә кертелгән үзгәрешләр расланды.

2017 елда тәҗрибә алмашу кысаларында Хисап палатасында Камчатка крае Тикшерү-хисап палатасы Рәисе С.В. Лозовский, Севастополь шәһәренең Тикшерү-хисап палатасы делегациясе белән эшлекле очрашулар оештырылды.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары союзы белән үзара хезмәттәшлек

Хисап елында Татарстан Хисап палатасы муниципаль финанс тикшерүе нәтиҗәлелеген арттыруга, республика тикшерү-хисап органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшен дәвам иттерде.

Муниципаль тикшерү-хисап палаталарына оештыру, хокукый, методик, мәгълүмати ярдәм күрсәтелә. Барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округларының тикшерү-хисап органнарына кураторлар – Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторлары һәм структура бүлекчәләре җитәкчеләре беркетелгән.

Ай саен муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенә мониторинг үткәрелә.

Июньдә Ульяновскида МТХО Союзы төзелүнең 15 еллыгына багышланган Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары союзы әгъзаларының Гомуми җыелышы (XVI Конференциясе) булып узды.

Конференция эшендә 120 дән артык кеше катнашты. Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы Рәисе А.И. Демидов җитәкләгән Татарстан Республикасы делегациясе составына Хисап палатасы вәкилләре һәм республиканың муниципаль тикшерү-хисап органнарының 13 җитәкчесе керде.

Фикер алышулар барышында конференциядә катнашучылар тарафыннан Хисап палатасының тышкы яктан финанс тикшерүен камилләштерүдәге уңай тәҗрибәсе билгеләп үтелде.

Конференция уздыру кысаларында шулай ук «Россия Федерациясе субъектларында тикшерү-хисап органнары берләшмәләренең (советлар, ассоциацияләр) эш тәҗрибәсе» дигән темага түгәрәк өстәл булып узды, аның барышында Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы Рәисе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И. Демидов аудиториягә тышкы финанс тикшерүе муниципаль органнары белән үзара хезмәттәшлек турында мәгълүмат җиткерде.

2017 елның декабрендә булып узган Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары Советы утырышында хисап елында республиканың тышкы финанс тикшерүе органнарының эш йомгаклары, җир һәм милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә, муниципаль белем бирү учреждениеләрендә бозуларны һәм кимчелекләрне ачыклау буенча тикшерү эшчәнлеге практикасы, бюджет законнары өлкәсендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру, Хисап палатасы һәм муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары белән берлектә һәм параллель тикшерү һәм экспертиза-аналитика чараларын оештыру һәм уздыруны

стандартлаштыру мәсьәләләре каралды, 2018 елга республика тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре билгеләнде.

Утырыш эшендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе Леонид Якунин катнашты һәм чыгыш ясады.

Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы эшчәнлеге һәм үткәрелә торган чаралар турында мәгълүмат, норматив һәм методик документлар Татарстан Республикасы Хисап палатасының (http://www.sprt.tatar/) һәм Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советының (http://www.ksort.ru) рәсми сайтларында урнаштырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек

2017 елда Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы (алга таба – Совет) эшчәнлеге кысаларында финанс тикшерүе органнары һәм хокук саклау органнарының үзара хезмәттәшлеген үстерү буенча эш дәвам иттерелде. Финанс тикшерүе органнары һәм хокук саклау органнарының үзара хезмәттәшлеге Тикшерү чараларының җыелма планына туры китереп тормышка ашырылды.

Финанс-бюджет өлкәсендә бозуларны кисәтү һәм профилактикалау максатында министрлыкларга, ведомство һәм республиканың муниципаль берәмлекләренә ел саен дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары тарафыннан ачыклана торган бозулар һәм кимчелекләрне анализлау һәм системалаштыру нәтиҗәләре буенча Бәяләмә җибәрелә.

Апрельдә булып узган Совет утырышында дәүләт һәм

муниципаль милек объектлары һәм милке белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру, милекне тотуга бюджет чыгымнарын оптимизацияләү буенча чаралар тикшерелде.

Проблемалы мәсьәләләрне анализлау һәм тиешле тәкъдимнәр әзерләү өчен Хисап палатасы, Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләреннән торган махсус эшче төркем булдыру турында карар кабул ителде.

Декабрьдә узган Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләр буенча ведомствоара координацияләү советы утырышында көн тәртибенең төп мәсьәләсе булып республиканың дәүләт һәм муниципаль финанс тикшерүе органнары эшчәнлегенә мәгълүмати технологияләрне кертү процессы торды.

Совет утырышы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Хисап палатасы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты, Федераль Казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы вәкилләре составында дәүләт һәм муниципаль финанс тикшерүе органнары эшчәнлегенә мәгълүмати технологияләрне кертү буенча эшче төркем булдыру турында карар кабул ителде.

Совет утырышында Дәүләти (муниципаль) милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча методик тәкъдимнәр хупланды, алар Татарстан Республикасы министрлыкларына, ведомстволарына һәм муниципаль берәмлекләренә җибәрелде.

Хисап палатасы аудиторлары Сергей Колодников һәм Азат Вәлиев февральдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча комитеты утырышында катнашты һәм

Татарстан Парламенты йөкләмәләре буенча үткәрелгән тикшерү чараларының: Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына гаилә терлекчелек фермаларына ярдәм итүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын максатчан һәм нәтиҗәле куллануны тикшерү һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына караган һөнәри белем бирү оешмалары тарафыннан дәүләт ресурсларын нәтиҗәле куллануга карата үткәрелгән аудит йомгаклары турында докладлар белән чыгыш ясадылар.

Мартта әлеге аудит нәтиҗәләре турындагы Хисап палатасы Хисабы Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты утырышында тәкъдим ителде.

Декабрьдә Хисап палатасы аудиторы Илнур Мөбарәков Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты утырышында катнашты һәм республиканың кадетлар белем бирү учреждениеләрендә патриотик һәм хәрби тәрбиягә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануга карата нәтиҗәлелек аудиты нәтиҗәләре турында доклад белән чыгыш ясады.

Сентябрьдә һәм октябрьдә Хисап палатасында Татарстан Республикасы Президенты Аппараты вәкилләре катнашында, Татарстанга Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан тормышка ашырыла торган персонал белән идарә итүнең хәзерге заман технологияләрен кертү һәм тәҗрибә алмашу буенча проекты кысаларында, Башкортостан, Коми һәм Марий Эл, Тува республикаларыннан, Волгоград, Владимир, Ленинград, Липецк, Ростов, Тамбов һәм Ульяновск өлкәләреннән, Ставрополь краеннан һәм Севастопольдән килгән дәүләт органнарының кадрлар буенча белгечләре белән эшлекле очрашулар булды.

Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе белән хезмәттәшлек кысаларында 2017 елда Хисап палатасы вәкилләре Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү курсларын, һөнәри әзерлек программаларын үткәрүдә катнаштылар.

Мартта Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидовка «Дуслык» ордены тапшырды. Тышкы финанс тикшерүе җитәкчесе Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә күпъеллык хезмәте һәм Татарстан Республикасы бюджет үтәлешенә дәүләт тикшерүен тормышка ашыруга зур өлеш керткәне өчен бүләкләнде.

Сентябрьдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының XXII утырышында депутатлар яңа алты еллык вакытка Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазифасына билгеләү өчен А.Ш. Вәлиев кандидатурасын бертавыштан раслады.

Эшчәнлектә хәбәрдарлык

2017 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге, Хисап палатасы Коллегиясе, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү Советы һәм Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советы утырышлары даими рәвештә массакүләм матбугат чараларында яктыртылып торды.

Хисап чорында массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет басмалар, журналлар, газета һәм телевидение) Хисап палатасы эшчәнлеге 373 материалда, шул исәптән федераль һәм региональ басмаларда: «Интерфакс-Поволжье», «РБК», «РЕГНУМ», «Татар-информ», «Кабардино-Балкария», «Нева-инфо», «Мангазея» (Петропавловск-Камчатский) мәгълүмат агентлыкларының веб-сайтларында, «БизнесOnline» һәм «Реальное время» электрон газеталарында, «E-gorlovka.com.ua», «Красноярские новости», «РыбинскOnline», «Твой город Псков», «ForPost.ru» (Севастополь) веб-сайтларында, «Аргументы и Факты», «Коммерсантъ», «Независимая», «Комсомольская правда»,

«МК», «Российская газета», «Известия» газеталарының региональ чыгарылышларында, «Вестник АКСОР», «Финконтроль», «Татарстан», «Чаян» журналларында тәкъдим ителде.

Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат рәсми сайтта (http://www.sprt.tatar), Россия Федерациясе Хисап палатасы һәм Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары порталында (http://www.portalkso.ru) урнаштырылды. Республика Хисап палатасы сайтында шулай ук даими рәвештә уздырылган тикшерү чаралары йомгаклары буенча видеоматериаллар урнаштырылды.

2017 елда Хисап палатасы сайтына 29 517 тапкыр керү теркәлгән.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары, Хисап палатасы эшчәнлеге хроникасы квартал саен Татарстан Республикасы Хисап палатасының мәгълүмати бюллетеньнәрендә басылып чыкты. Бюллетеньнар Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына юлланды.